**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 11 апрель | № 244

г. Казань

Әлмәт муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре» ачык акционерлар җәмгыятенең Әлмәт муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 0,0411 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:07:100001:2714 кадастр саны белән кадастр паспортында күрсәтелгән чикләрдә Әлмәт район нефть үткәрү идарәсенең «Әлмәт – Кәләй» магистраль нефтьүткәргечендә (югары күкертле) «Кәләй» нефть суыртып агызу станциясенә кергәндә, «Кәләй» нефть суыртып агызу станциясенә кергәндә нефть күләмен һәм сыйфатын үлчи торган оператив система, «Яр Чаллы – Әлмәт» магистраль нефть үткәргече тармагы, «Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре» ачык акционерлар җәмгыяте объектын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә күчемсез мөлкәт дәүләт кадастры документларына һәм Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков